| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.06.2022 г.Казань № 554

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гражданнарның аерым категорияләре өчен дә гамәлдә булуы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Билгеләргә:

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гамәлдә булуы 2022 елның 31 декабренә кадәр шулай ук туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән, түбәндәге категорияләрнең берәрсенә карый торган гражданнарга да кагыла:

эштән азат ителү куркынычы янаган гражданнар (оешма бетерелүгә яки шәхси эшкуарның эшчәнлеге туктатылуга, оешмада, шәхси эшкуарда хезмәткәрләрнең саны яки штаты кыскартылуга һәм алар белән хезмәт шартнамәләрен өзү ихтималлыгына бәйле рәвештә эштән китәргә җыенучы гражданнар);

эш бирүче зат инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яки) тулы булмаган эш атнасы режимына күчерелгән гражданнар;

эшне вакытлыча туктатып тору турында карар кабул иткән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар;

үзләренә карата бөлгенлек (банкротлык) турында процедуралар кулланылган эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар;

эш хакын сакламыйча отпуск ялларында булган гражданнар;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар.

1.2. Әлеге пунктның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар, башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри тапшырылырга тиешле документларга өстәмә рәвештә, категориягә карап, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә эш бирүче тарафыннан бирелгән, түбәндәгеләр турында карар кабул ителүен раслый торган түбәндәге документларның берсен тапшыралар:

оешманы бетерү яки шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекне туктату турында;

оешмада, шәхси эшкуарда хезмәткәрләр санын яки штатын кыскарту һәм хезмәт шартнамәләрен өзү ихтималлыгы турында;

эш бирүче тарафыннан тулы булмаган эш вакытын билгеләү турында;

эшләрне туктату яки вакытлыча туктатып тору турында;

хезмәт хакын сакламыйча гына отпусклар бирү турында;

хезмәткәрләрне азат итү буенча чаралар үткәрү турында.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2022 елның 25 мартыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов